

# Татар халкының каһарманы – Муса Җәлил

# Сугыш еллары



1941 елның июль аенда М. Җәлил армиягә алына. Башта ул Казан гарнизоны хәрби частендә рядовой кызылармеец булып хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге политработниклар әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә фашист гаскәрләре якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә эвакуацияләнә. 1941 елның декабрендә курсларны тәмамлагач, өлкән политрук М. Җәлил Мәскәү аша фронтка китә.

Шагыйрь сугышка кадәр үк дөньяның сәяси картасында туган үзгәрешләрне үткер күзләре белән күзәтеп килде, фашизмның баш калкытуын күреп, хәвефләнүле шигырьләрен язды. Фашизм белән көрәшкә, батырлыкка ул рухи яктан алдан ук әзерләнеп, идея ягыннан чынығу алып килде. Шуңа күрә сугыш башлану белән үзен солдат итеп хис итте, үзен дә, иҗатын да фашизм белән көрәшкә багышлады. “Әйдә, җырым!” шигырендә ул сугыш башлангач туган рухи халәтен түбәндәгечә билгеләде:

Вакыт җитте...
Хәзер ярты юлда
Куеп торып тыныч эшемне,
Багышларга Ватан сугышына


Смерть немецким оккупантам!
ОТВАГА
Ежедневная красноармейская газета
№ 445. Пятница, 1 мая 1942 г.

ПРИКАЗ
ВОЙСКАМ АРМИИ
1 мая 1942 г. № 32 Действующая армия

Товарищи красноармейцы, командиры и политработники!

Поздравляю вас с международным праздником трудящихся — 1 мая — днем смотра боевых сил рабочего класса.

Первое мая 1942 года наша родина, ее доблестные вооруженные силы отмечают в условиях Великой отечественной войны против немецких захватчиков. Одиннадцатый месяц идет жесточайшая битва с озверелым врагом, коварно напавшим на нашу страну. Эта битва советского народа идет за свободу, культуру, честь и независимость нашей родины.


Истекшая зима принесла Красной армии значительные победы над врагом. Осуществляя гениальные стратегические планы Великого СТАЛИНА, под его испытанным водительством Красная армия, наступая, нанесла сокрушительные удары немецкой грабь-армии. Уничтожены лучшие силы врага, вместе с ними громадное количество техники и вооружения. Алый стяг Страны Советов снова взвился над многими городами, тысячами сел и деревень, освобожденных Красной армией от гитлеровских поработителей.

Немеркнущей славой войдут в историю Отечественной войны зимние бои наших ударных частей на Волховском рубеже. С жесточайшими боями прошли Вы, товарищи, свыше ста километров, освободили более ста сел и деревень Ленинградской области. Истреблены тысячи немецких солдат и офицеров, не счи-

Сугышның беренче айларында язылган шигырьләрендә фикер һәм хис турыдан-туры ачыктан-ачык өндәү һәм чакыру рәвешендә, публицистик кайнарлык белән ачыла. Ул халыкны  изге көрәшкә чакыра, бөтен көчне дошманны җиңү өчен тупларга өнди. Шагыйрь  “котырган этнең безнең корыч сафка таш маңгаен бәреп ярачагына” нык ышана.



1942 елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, аларның часте чолганышта калып, М. Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә.



# 791 көн әсирлектә




1942 елның июненнән Җәлилнең маҗаралы героик тормышы башлана.
Шагыйрь үзенең тоткынлыктагы тормышын әкияттәге
серле йомгак белән чагыштыра:

Әкияттәге серле йомгак булып
Җырым калды сүтелеп юлымда,
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине соңгы йөрәк җырымда.

**Шигырьдәге эпитетлар да авторның мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. Җәлил, мәсәлән, фашист майорын “бакыр күзле” дип атый. Бу – оста тотып алынган портрет детале. Ул деталь фашистның кансызлыгы турында сөйли, кешелексезлегенә ишарә ясый. “Кургаш болытлар”, “моңлы кояш” кебек эпителар да сурәтләнгән күренешнең киеренкелегенә туры килә.**

**Муса Җәлил иҗатының сәнгатьчә байлыгы – шагыйрь характерының ныклыгында һәм рухи байлыгында.Ул шигырьләрдә шагыйрьнең корыч кебек нык характеры, гаҗәеп кешелекле бай рухи дөньясы ачыла.**
**Җәлил “Кошчык”шигырендә (1942) фашистлар кулына тоткын булып эләккән, “аяк- куллары чәнечкеле чыбык белән бәйләнгән “, әмма рухы богауланмаган шагыйрь образын сурәтләде.**

Төрмәнең караңгы, тар, таш бүлмәсендә бөтен Җир шарын йөрәгенә
сыйдырган нечкә күңелле, кешелекле шагыйрь яши.
Үзенең үләсен белеп, дөньяның олылыгын
тоеп, киләчәкнең үзе көткәнчә булачагына омтылып яши. Яши
генә түгел, көрәшә: шигъри сүзе белән, фәлсәфәсе, мәхәббәте белән...
Ватанга мәхәббәт һәм сөйгәненә мәхәббәт аның йөрәгендә
гә яши:




Илдән киттем ил һәм синең өчен,
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алыштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?!
Сиңа миннән хәбәр китәрсәләр,
“Муса инде үлгән”, - дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.


**“Катыйльгә”, “Дуска “ кебек лирик шигырьләрендә дә шагыйрьнең көрәш рухы белән сугарылган образлы, батырлык фәлсәфәсе ачыла. Бу шигырьләрнең күп юллары хикмәтле сүз, афоризм булып яңгырый. “Вәхшәт” шигырендә фашистларның вәхшәтен хисси яктан тагын да көчлерәк ачу һәм шигырьнең фикерен тирәнәйтү өчен, табигать күренешләренә урын бирелә. Ату-үтерүләрне күргән Җир-ана, балалар кебек, үкси-үкси яшь түгә, көзге урман нәфрәтеннән шашып шаулый:**

**Күк күкрәде кинәт, җил сызгырды,**
**Җил елады кысып тешләрен.**
**Нинди ачы бу яшь, нинди кайнар!..**
**Нишләдең син, җирем, нишләдең?**

**Җәлил бу вәхшәтне, гомумән сугышны, тарихның, кешелекнең олы фаҗигасе итеп күрә һәм шигырен шушы вәхшилеккә каршы юнәлгән сугышчан чакыру белән тәмамлый. Бу шагыйрьнең сугышны танып-белүдәге һәм сурәтләүдәге яңалыгы булды. Кешелеккә фашизмның нинди вәхшәт китерүен әнә Җәлил шундый сәнгатьчә югарылыкта ачты.**

“Моабит дәфтәрләре” – Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Сугышка кадәрге иҗатында ирешелгән казанышлар биредә тагын да үстерелде, баетылды. Шагыйрьнең сугыш эчендә кеше, солдат һәм әдип буларак олы сынау үтте, зур фаҗига кичерүе, искиткеч шартларада рухи көрәш алып баруы аның сәнгатьчә осталыгын да үткенәйтте, шигъри хисләрне дә яңа биеклеккә күтәрде.






Җәлил шигырьләре халкыбызның рухи дөньясына яңа байлыклар өстәде, әдәбиятыбыз мирасына кыйммәтле хәзинә булып керде һәм шагыйрьгә үлемсезлек алып килде. Татар әдәбиятына шундый олы байлык биргән шагыйрь 1957 елда Ленин премиясе белән бүләкләнде.



**Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә**
**Ленин премияләре буенча**
**СССР Министрлар Советы янындагы комитетта**
**Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә**
**аеруча күренекле казанышлар өчен**
**Ленин премияләре бирү турында**

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премияләре комитеты аеруча күренекле әдәбият, музыка, сынлы сәнгать әсәрләре өчен һәм театр сәнгате эшлекләләренең аеруча күренекле казанышлары өчен 1957 елгы Ленин премияләре бирергә карар бирде:

1. Сергей Тимофеевич Коненковка —«Автопортрет» скульптурасы өчен.
2. Леонид Максимович Леоновка — «Рус урманы» романы өчен.
3. Муса Җәлилгә — «Моабит дәфтәре» исемле шигырьләр циклы өчен.
4. Сергей Сергеевич Прокофьевка — Җиденче симфония өчен.
5. Галина Сергеевна Улановага — балет сәнгатендәге күренекле казанышлары өчен.





Муса Җәлил халкыбызның бөек улы булып танылды. Аның исеме белән шәһәр һәм колхозлар, теплоход һәм
аерым коллективлар атала. Сыны  һәйкәлләрдә гәүдәләнә, батырлыгы җырларда җырлана. Җәлил хәзер үзе  әдәби геройга – поэма, кино, драма, роман, операларның героена әверелде.
Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, Т.Миңнуллин, И.Юзеев, Д.Вәлиев аңа багышлап пьесалар, ә Ш.Маннур, Г.Әпсәләмов романнар яздылар. Татар язучылары   гына түгел, рус, казакъ, калмык шагыйрьләре дә Җәлил турында поэмалары   иҗат итте.
 Немец язучысы Эрих Мюллер пьеса һәм телевидение өчен сценарий язды,  ул Германиядә күрсәтелде.  Н.Җиһановның “Җәлил” операсы (Ә.Фәйзи либреттосы) Мәскәүнең Зур театрында да, Чехословакиядә  дә уңыш белән барды. “Ленфильм” студиясе “Моабит дәфтәре” исемле кино чыгарды.
Муса Җәлил музейлары да күп нәрсә турында сөйли.

# Муса Җәлил музее



Муса Җәлил музее ике янәшә квартирны биләп тора.
Беренче квартирда мемориаль музей,
икенче квартирда күргәзмәләр залы
һәм әдәбият салоны урнаштырылган.






Музей фонды составында:
М.Җәлил тормышы һәм иҗат юлына багышланган басмалар,
М.Җәлилнең басма әсәрләре,

Үзенең халыкчан иҗаты,
үлемсез шигырьләре белән Муса Җәлил
халкыбызның рухи
тормышында бүген дә актив катнаша. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк:

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне,
“Үлем” диеп әйтеп буламы соң,
Җиңеп үлгән мондый үлемне?
(“Ышанма”, 1943).

Бүгенге көрәштә Муса Җәлил дә үзенең шигырьләре белән бер сафта атлый.
Ул якты һәм матур тойгылар тәрбияли, кешеләрдәге һәм тормыштагы
матурлыкны күрергә һәм шул матурлык өчен көрәшергә



**Дөнья халыклары аның һәм аның көрәштәшләренең батырлыгы каршында баш ия, үлемсез шигырьләрен үзенеке итеп күңеленә ала.**
**Шагыйрь сурәтеннән ниндидер тылсымлы балкыш бөркелә сыман. Бу балкыш безне һәрчак үзенә дәшә.Намуслы яшәргә, бернинди кыенлыклар алдында сынатмаска чакыра. Муса Җәлил эзләре буйлап эзләгәндә мин шуңа ышандым.**
**Татар халкының шундый бөек кешеләре булуы һәм шул халыкның мин дә бер вәкиле булуым белән бик тә горурланам.**
**Бүгенге көндә минем милләтем - Муса Җәлиле булган бөек милләт ул.**
**Ул безнең горурлыгыбыз, мактанычыбыз,**
**кешелек дәрәҗәбез. Муса Җәлил урамы, Муса Җәлил музее .. Шагыйрь иҗаты, шөкер, мәңгеләштерелгән. Бу шулай булырга тиеш тә.**
**Без, хәзерге буын кешеләре, Туган илебезне Җәлил кебек яратырга һәм аңа тугрылыклы булырга тиешбез!**